**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 18 июнендәге 2531 номерлы карары**

**Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны**
**карап тоту өчен түләү күләме турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милек белән идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле булмаган сыйфатта һәм (яки) билгеләнгән дәвамлылыкны арттырып җибәргән өзеклекләр белән хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелыш карарын кабул итмәгән күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләре өчен хезмәтләрнең төрләре буенча торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен (кушымта) билгеләргә, 2024 елның 1 июленнән башлап гамәлгә кертергә.

2. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, шулай ук гомуми җыелышта күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен күпфатирлы йортта гомуми милектән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү составына керүче түләү

күләме күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә билгеләнә, дип билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләренә (Р.Р.Фәтхетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Х.Шәмсетдинов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (В.А.Лысачкин) торак урыннар милекчеләренә, алар тарафыннан күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр исемлеген һәм торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү мәсьәләсе буенча җыелышлар үткәргәндә, методик һәм консультацион ярдәм күрсәтергә.

4. Күпфатирлы йортта торак урынны карап тоту өчен түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләр составына, күпфатирлы йортның конструктив һәм техник характеристикаларына бәйле рәвештә исәпләнә һәм үзгәртелә, дип билгеләргә.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 21 июнендәге 1749 номерлы «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме турында» карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 18 июнендәге 2531 номерлы карарына кушымта

**2024 елның 1 июленнән социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелыш карарын кабул итмәгән күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләре өчен хезмәтләрнең төрләре буенча торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме**

| № т/б | Түләүнең исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Күпфатирлы йорт белән идарә итү | Аена торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. өчен | 4,75 |
| 2 | Күпфатирлы йортның гомуми милеге составына керә торган гомуми файдалану урыннарын карап тоту, шул исәптән:<br>- гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру;<br>- йорт яны территориясен җыештыру;<br>- чүп үткәргечкә хезмәт күрсәтү;<br>- дератизация (дезинсекция);<br>- контейнер мәйданчыкларын карап тоту | Аена торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. өчен | 2,92;<br>5,15;<br>1,07;<br>0,18;<br>0,37 |
| 3 | Төзелеш конструкцияләренә, биналарның инженерлык системаларына һәм башка гомумйорт милкенә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән:<br>- торак урын;<br>- лифтлар;<br>- телевидениене күмәк кабул итү системалары; | Аена торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. өчен | 5,16;<br>4,44;<br>0,62; |
| 1 | 2 | 3 | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - күмәк (гомумйорт) исәпләү приборлары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборы белән җиһазландырылган һәм кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборы белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборы белән җиһазландырылмаган һәм кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборы белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборы һәм жылылыкалмаш җайланмасы белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборы, жылылыкалмаш җайланмасы һәм күтәргеч насос станциясе белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- күмәк (гомумйорт) исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылмаган һәм күтәрү насос станциясе белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- күмәк (гомумйорт) исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылмаган һәм жылылыкалмаш җайланмалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары; | | 3,22;<br>3,49;<br>3,88;<br>4,15;<br>4,48;<br>4,78;<br>3,52;<br>4,21; |
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| | - күмәк (гомумйорт) исәпкә алу приборлары | | 4,51; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белән җиһазландырылмаган һәм җылылыкалмаш җайланмалары һәм күтәрү насос станциясе белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары;<br>- җылылык энергиясен исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборлары һәм җылылык чыгымнарын автомат рәвештә җайга салу системалары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге үзәк җылыту системалары;<br>- җылылык энергиясен исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылмаган һәм җылылык чыгымнарын автомат рәвештә җайга салу системалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге үзәк җылыту системалары;<br>- җылылык энергиясен исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган һәм җылылык чыгымнарын автомат рәвештә җайга салу системалары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге үзәк җылыту системалары;<br>- җылылык энергиясен исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборлары һәм җылылык чыгымнарын автомат рәвештә җайга салу системалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге үзәк җылыту системалары;<br>- йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләре һәм электр җиһазлары;<br>- күпфатирлы йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системалары;<br>- газ кулланучы җиһазлар гомуми файдалану урыннарында урнашкан күпфатирлы йортларда (мәсәлән, элек тулай торак буларак кулланылган йортлар һ.б.) йорт эчендәге газ җиһазлары системалары;<br>- эчке янгынга каршы суүткәргечнең автоматик янгын сигнализациясе системалары; | | 2,61;<br>3,23;<br>3,27;<br>3,89;<br>1,68;<br>0,27;<br>0,37;<br>1,85; |
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| | - вентиляция каналлары;<br>- төтен юллары | | 0,40;<br>0,71 |
| 4 | Йорт эчендәге газ җиһазына техник диагностика ясау (түләү диагностика ясау вакыты башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә) | Аена торак урынның гомуми мәйданының | 1,09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 1 кв.м. өчен | |

Искәрмә. Тарифлар өстәлгән бәягә салымны исәпкә алып билгеләнгән.